Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә якынча җаваплар (мәктәп туры, 2017-2018 уку елы). 9 нчы сыйныф

Максималь балл – 44.

I. Теоретик биремнәр. (9 балл)

1. Матур әдәбиятка хас төп өч сыйфатны аерып билгеләгез һәм язып куегыз. (6 балл)

Чынбарлыкны сүз, образ ярдәмендә тудыра, кешене үзәккә куеп сурәтли, язучының фикер-карашларын чагылдыра h.б.

2. Түбәндә аталган әсәрләрнең кайсылары гомумтөрки әдәбиятка карый. (3 балл)

А) **Күлтәгингә багышланган каберташ язмасы**
Б) "Идегәй"
В) **"Диване лөгатет-төрк"**
Г) "Җил иясе җил чыгара"
Д) **"Котадгу белек"**

II. Әдәби әсәргә кагылышлы биремнәр. (20 балл)

1. Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" яки Котбның "Хөсрәү вә Ширин" әсәрендә геройларның эш-гамәлләре аша нинди сыйфатлар хуплана, ниндиләре тәнкыйтләнә, кире кагыла? Аерып куеп, санап чыгыгыз. (10 балл)

Кол Гали "Кыйссаи Йосыф": хуплана – гаделлек, сабырлык, эти-әнигә, якыннарга мәхәббәт, гафу итә белү, матурлык h.б., тәнкыйтләнә – көнчелек, сабырсызлык, үз мәнфәгатьләреңне генә алга кую h.б.

2. Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" яки Котбның "Хөсрәү вә Ширин" әсәрендә җиткерелгән төп идеяне ачыклап языгыз, укучыга нинди фикер әйтелә? (5 балл)

3. Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" яки Котбның "Хөсрәү вә Ширин" әсәрендә автор идеалын чагылдырган геройның исемен яки исемнәрен атагыз. (5 балл)

Фәрхад, Йосыф

II. Иҗади эш. (15 балл)

Соңгы елларда киң кулланылышта булган *компьютер, ноутбук, телефон, планшет, телевизор* турында 5 мәкаль уйлап чыгарып языгыз.